ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 30 » гыйнвар 2018 ел** **№ 72**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6964 сум 68 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елга җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеген раслау турында» 2017 елның 31 гыйнварындагы 95 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин

Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
______________ 2018 ел, №____
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең**
**БӘЯСЕ**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3775-10 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 455-91 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1470-30 |
| **Барлыгы** | **5701-31** |

Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
_______________ 2018 ел, №____
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең**
**БӘЯСЕ**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 205-15 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3569-95 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 455-91 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1470-30 |
| **Барлыгы** | **5701-31** |